| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 августа 2020 г. № 3745

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү аның предметы булган муниципаль контрактлар төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктның 3 абзацы, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү аның предметы булган муниципаль контрактлар төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 5 августындагы
3745 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү аның предметы булган муниципаль контрактлар төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очракларда, расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган срокка дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзү турында карарлар кабул итү тәртибен билгели.

2. Муниципаль заказчылар муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен, мондый муниципаль контрактлар төзү турында Башкарма комитет карары белән каралган акчалар чикләрендә һәм срокта, эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзергә хокуклы.

3. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен, эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар, шулай ук шартларында аларны үтәү предметларына бәйле булмаган каршы йөкләмәләр күздә тотылган, расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган срокка муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар кайтаруга муниципаль контрактлар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль программалар кысаларында төзелергә мөмкин.

4. Әлеге тәртипнең 3 пунктында каралган муниципаль контрактлар, мондый программаларда сатып алулар объектларының һәр сатып алу объектына карата күрсәтелгән түбәндәге мәгълүматны билгеләү шарты белән, муниципаль программаларның тиешле чараларын тормышка ашыруга каралган акчалар чикләрендә һәм срокка төзелә:

1) әгәр муниципаль контракт предметы булып эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү торса:

сатып алу объектының исеме;

эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;

сатып алуларны гамәлгә ашыру сроклары;

еллар буенча бүлеп, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләренә түләү өчен акчаның иң чик күләме;

2) әгәр муниципаль контракт предметы булып товарлар кайтару торса:

сатып алу объектының исеме;

сатып алуларны гамәлгә ашыру сроклары;

каршы йөкләмә предметы һәм аны үтәү срогы;

еллар буенча бүлеп, кайтарылган товарларга түләү өчен акчаның иң чик күләме.

5. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә әлеге кагыйдәләрнең 4 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль контрактлар мондый муниципаль контрактлар төзү турында түбәндәгеләрне билгели торган Башкарма комитет карарында каралган акчалар чикләрендә һәм срокта төзелә:

1) эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырылган нәтиҗәләре;

2) эшләр, хезмәтләр күрсәтү составын тасвирлау;

3) подрядчыларны, башкаручыларны билгеләү өчен кирәкле срокларны исәпкә алып, эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең иң чик срогы;

4) еллар буенча бүлеп, озак сроклы муниципаль контракт өчен түләүгә акчаларның иң чик күләме.

6. Муниципаль контракт төзү турындагы карар Башкарма комитет карары рәвешендә кабул ителә.

7. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен эш башкаруны, хезмәт күрсәтүне башкару циклының дәвамлылыгы расланган бюджет лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзү турында әлеге кагыйдәләрнең 5 пунктында каралган Башкарма комитет карары проектын (алга таба – Башкарма комитет карары проекты) әзерләүне һәм чыгаруны тәэмин итүне Башкарма комитетның тиешле эшчәнлек өлкәсенә кураторлык итүче тармак органы гамәлгә ашыра.

8. Башкарма комитет карары проекты Башкарма комитетның Эш регламентында билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитетның финанс идарәсе һәм хокук идарәсе белән килештерелергә тиеш.

9. Башкарма комитетның финанс идарәсе, түбәндәге шартлар үтәлгәндә, Башкарма комитет карары проектын алган датадан башлап 15 эш көненнән дә артмаган срокта күрсәтелгән карар проектын килештерә:

1) агымдагы финанс елында һәм план чорында муниципаль контракт өчен түләүгә каралган акчаларның иң чик күләме тиешле финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре күләменнән артмау;

2) план чорыннан тыш муниципаль контракт өчен түләүгә каралган акчаларның еллык чик күләме план чоры чикләрендә (агымдагы финанс елында) күрсәтелгән муниципаль контракт өчен түләүгә максималь еллык акчалар күләменнән артмау.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева